***Безнең йөрәкләрдә син, Тукай!***
***Әдәби-музыкаль кичә.***

Максат: Балаларда бөек шагыйребез Г.Тукайның шигырьләренә кызыксыну уяту; фикерләү, иҗади сәләтләрен һәм сөйләмнәрен үстерү; милли үзаң, үз халкың белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Зал бәйрәмчә бизәлә.

***"Тукай маршы"(З.Хәбибуллин музыкасы) уйнатыла. Сәхнә алдына ике укучы чыгып баса. Көй әкренләп тына.***

**1 нче алып баручы**. ***Аделя***

Хәерле көн, хөрмәтле укытучылар, укучылар!

Һәр елны салкын кыш үтеп, яз җиткәч, халкыбыз бөек Тукайның туган көнен билгеләп үтә. Бүген 26 апрель – татар халкының сөекле улы, сәнгать дөньясында маяк булып мәңге яши, яшьни торган Тукаебызның Туган көне.

**"Безнең йөрәкләрдә син, Тукай!"** дигән кичәбез шагыйрьнең туган көненә багышлана.

**2нче алып баручы**. ***Ләйлә***

Әйләнәндә гөлләр
Тормыш якты!
Бәйрәм хисе бүген күңелдә!
Туган көнең белән!- диләр
Горурланып һәркем бу көндә.
Килә, килә..Язлар саен сиңа
Илең килә туган көнеңдә.
Бетми торган гомерен кушкан сыман
Синең бөек кыска гомергә.

**1нче алып баручы.**

Телсез идек, Тукай безне телле итте.
Җырсыз идек, Тукай безне җырлы итте.
Күгебездә балкып торган йолдыз булып,
Кара төндә өстебезгә энҗе сипте.

Әйе, Тукай якты йолдыз, сүнмәс йолдыз булып калыкты.

Габдулла Тукай дөньяда бары тик 27 ел гына яшәгән, нибары 8 ел гына иҗат иткән. Шулай булса да ул гаять зур, бәя биреп бетермәслек рухи байлык калдырган. Шагыйрьнең үлемсез әсәрләре безнең йөрәгебездә мәңгелек урын алды.

Бүген исә карты да, яше дә Тукайны укый, аны олылап искә ала, бәйрәм итә.

**"Бәйрәм бүген" җыры башкарыла. (4а сыйныф укучылары)**

**2 нче алып баручы**.

Күп китапларның арасында
аның китаплары-
Ап-ачык нурлар чәчеп,
күренеп тора һәр яклары.
Алса, укыса халык шигырен аның-
истә кала,
Һәм аның шигыре халык күңеленә
зур хис сала.

Сөекле шагыйребезнең шигырьләрен яшь чакта бабаларыбыз ятлаган, әти-әниләребез укып үскән, хәзер аларны без өйрәнәбез. Тукай әсәрләрен укыган саен укыйсы килә. Алар җанны җылыта, күңелне яктырта, туган телгә мәхәббәт тәрбияли. Шагыйрь шигырьләре аша үзенең киңәшләрен бирә. Шундый шигырьләреннән берсе- “Су анасы”.

**“Су анасы” шигыре. (6в сыйныф укучылары)**

Салмак кына **“Бишек җыры”** ның көе ишетелә башлый. Бишек тирбәткән ана җыры яңгырый.

Әлли- бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып китәр бу,
Йокла, углым, йом күзең,
Йом,йом күзең, йолдызым.
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрмен;
Сиңа теләк теләрмен.
Бәхетле бул диярем.
Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсез, син.

**2нче алып баручы.**

Әйе, Г.Тукай нәниләрне бик яраткан, аларга багышлап бик матур, аңлаешлы шигырьләр язган. Аның шигырьләре сине туган көнеңнән алып гомереңнең ахырына чаклы озата килә.

**“Бала белән күбәләк” шигыре башкарыла. (1а сыйныф укучылары )**

**1нче алып баручы**.

Кызганычка каршы, күбәләкләр гомере кебек, шагыйрьнең дә гомере кыска була. Ул: “Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?”- дип яза, ләкин үз язмышы өчен беркемне дә гаепләми. Көннәрдән бер көнне Тукайның балачагы узган Кырлай урманнары, Казан арты кала. Аны Җаектагы туган апасы үз янына алдырта. Җизнәсе укырга, рус телен өйрәнергә мөмкинлекләр тудыра. Булачак шагыйрь белем дөньясына кереп чума. Мәдрәсәдәге дустыннан төрек телен дә өйрәнә.

**2нче алып баручы**.

Шагыйрь бала вакытында күргән һәр вакыйганы нәни йөрәге аша кичерә, үскәч аларны әсәрләрендә яктырта. Кырлай – шагыйрьнең күңеленә бетмәс-төкәнмәс иҗат көче биргән төбәк.

Иң матур җир кайда?- дисез,
Билгеле, Кырлай җире.
Барча әкият геройлары
Кырлайда туган инде,-

дип язуы белән шагыйрь хаклы.

Әкиятләрен сөйләп, тыңлап,
Телләребез ачыла.
“Су анасы”, “Шүрәле”ләр-
Безнең дуслар бары да.

Хәзер сезнең игътибарыгызга “Шүрәле” поэмасы геройлары белән очрашу тәкъдим итәбез.

**“Кызыклы шәкерт” шигыре (4в сыйныф укучылары)**

**1нче алып баручы.**

Әкиятләрдәге Шүрәлеләр
Кырлаенда яши бүген дә.
Шигырь чишмәләре җырга күчеп,
Яши сандугачлар телендә.
Ничә буын сине иң кадерле
Бер кешесе итеп сагына.
Син остаз да, мөгаллим дә булып,
Яшисең күк туган ягыңда.

**2нче алып баручы.**

Г.Тукайның балаларга багышланган әсәрләре, җыентыклары, китаплары безнең көннәрдә аеруча күпсанлы тираж белән һәм еш басылып тора. Хәтта кечкенә генә күләмле әсәрләре дә аерым китап итеп әзерләнә. Әйе, чынлап та, без бишектә чакта ук Тукайның көйләрен, җырларын ишетеп үсәбез, телебез Тукай шигырьләре белән ачыла.

**“Гали белән Кәҗә” шигыре. (Зарипов Ильйас)**

(Ишектән кулына печән тоткан Кәҗә, ә аның артыннан Сарык керә, ул бер читкәрәк сузылып ята.)

(3в сыйныф укычылары) **Кәҗә.** Безнең Гали мине бигрәк тә ярата инде, гел сусыл печән белән сыйлый.(Сарык янына килә) Әй, кортка, нишләп ятасың? Әйдә, тор, печән ашыйбыз. Әле ярый Гали бар, ул булмаса нишләр идек, чөнки әбинең дә печәне бетте.

**Сарык.** Әйдә, урманга барыйк, туйганчы бер үлән ашап кайтырбыз.

**“Кәҗә белән Сарык” әкиятеннән өзек.**

Китте болар. Бара, һаман бара, бара,
Күренмидер күзләренә ак һәм кара.
Бара болар. Күпме баргач, алла белә,
Юл өстендә үлгән бүре башын таба.
Курка башны кузгатырга Кәҗә-куркак,
Күптән инде куркаклыкта Сарык уртак,-
Баш янында болар икәү тора куркып,
Әйтешәләр бер-берсенә: “Син тот, мин тот!”
Кәҗә әйтә: “Сарык абзый, син көчлерәк”.

Сарык әйтә: “Син, сакалбай, гайрәтлерәк”.
Бүре башын кулга тотып кузгатырга
Юлдашларның берсенең дә җитми йөрәк.
Озак торгач шунда Кәҗә белән Сарык,
Бүре башын тоталмыйча, куллар барып,
Башны икәү тотып ике колагыннан,
Юнәлделәр, капчыклары эченә салып.

**Кәҗә белән Сарык бергә:**
Сандугачның балалары
Өздереп сайрый учакта.
Бүреләр дә качып бетте
Куркып Кәҗә, Сарыктан.
**Кәҗә.**
Инде өйгә кайтыйк, авылны да сагындым.
(Чыгып китәләр)

**1нче алып баручы**.
Туган илебезгә соклану, туган төбәккә таяну, аңа мәхәббәт – һәр кешенең күңелендә саклана торган хисләр. Аларны сәнгать осталары үзләренең җырларында, шагыйрьләр шигырьләрендә ачык чагылдырганнар. Андый хисләр бөек шагыйребез Тукай шигырьләрендә аеруча көчле.
Туган җир дә, туган тел дә бик кадерле
Юкка гына мактамаган аны Тукай.
Онытма син туган телең һичкайчан да
Туган җиреңне хөрмәтлә, ярат, дускай!

**“Туган авыл” җыры башкарыла. (6в сыйныф укучылары)**

**2нче алып баручы.**
Тукай – милли шагыйрь иде. Ул үз халкын, аның хезмәтен, гореф-гадәтләрен, бай телен чын күңелдән яраткан, аны өйрәнгән.Үзенең кыска гына гомере эчендә буыннан- буынга күчеп сөйләнерлек әсәрләр иҗат иткән шәхес ул. Тормышның ачысын-төчесен җитәрлек татыган, аны үзенең гүзәл әсәрләрендә һәрьяклап киң яктырткан.

**1нче алып баручы**.
Тукай исән, җыры күңелләрдә,
Яшәсәк тә үзен күрмичә.
Тукай килә моңлы сазын уйнап,
Шагыйрьләргә тынгы бирмичә.
Газраилләр юкка сөенгәннәр.
Карап шагыйрь яткан табутка
Аерылгысыз тоташ бер көч булып
Җаны яши аның халыкта.
Киләчәкне күреп бара шагыйрь,
Пар атлары күптән җигелгән.

Күчә Тукай яңа мәйданнарга
Халык йөрәгенең түреннән.

**“Пар ат” шигыре башкарыла. 5 в сыйныф укучылары**

**2нче алып баручы.**

Тукай “Уянгач, беренче эшем” дигән мәкаләсендә “Килер шундый заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле” дигән иде. Әйе, шагыйрьнең бу фикерләре тормышка ашты. Тукай образы әдәбиятта һәм сәнгатьтә күренекле урыннарның берсен алды. Тукай турындагы шигырьләрнең берничәсен тыңлап үтик:

**М. Әгъләмов “Тукай көне”. (Фатыхова Камиля 6в)**
**Равиль БУХАРАЕВ “Ночь Тукая” (Канунникова Полина 6в)**
**Булатов Булат Кәрим Әмири “Безнең авыл” шигыре**

**1нче алып баручы.**

Шагыйрь гомере, ни кызганыч, кыска була. Шул кыска гомерендә ул кайберәүләр 100 елда да үтеп чыга алмаслык эш башкарырга өлгерә. Шагыйрь бер дә икеләнмичә: “Халкым өчен яшәдем,аның белән бергә кайгырдым,аның бәхете өчен көрәштем”- дияргә хаклы. Шуның өчен дә Тукай безгә якын, кадерле, безнең йөрәкләрдә.

Халык гомере – мәңгелек диләр
Ә син, Тукай, халык куйнында.
Илең белән мәңге бергә син,
Мәңгелекнең олы юлында.

**“Туган тел” җыры белән тәмамлана.**